РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.07.2024 Буа шәһәре № 202 Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Шәһәр төзелеше эшчәнлегендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 гыйнварындагы 14 Бк/к номерлы «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» карары;

1.2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 244 Бк/к номерлы «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары;

1.3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 июнендәге 172 Бк/к номерлы «Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 13 августындагы 244 Бк/к карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентка үзгәрешләр кертү турында» карары;

1.4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 251 Бк/к номерлы «Капиталь төзелеш

объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында https://buinsk.tatarstan.ru. адрес ы буенча халыкка игълан ителергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Вәлиуловка йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов